Карар № 7

Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы
Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы

«19» декабрь 2025 ел — Олы Мәңгәр авылы

Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советынын .2019 елның 11 ноябрендәге 113 номерлы карары белән расланган «Олы Мәңгәр авыл җирлеге» муниципаль берәмлегендә Бюджет төзелеше һәм бюджет процессы турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында.

2025 елның 21 апрелендәге №84-ФЗ номерлы «Россия Федерациясе Бюджет кодексына һәм «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен туктатып тору, Россия Федерациясенең аерым закон актлары нигезләмәләрен гамәлдән чыгару һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларын 2025 елда үтәү үзенчәлекләрен билгеләү турында» Федераль законның 14 һәм 15 нче статьялары, Татарстан Республикасы Әтнә районы прокуратурасының 2025 елның 12 декабрендәге 020802-2025/ Прд 358 – 25 номерлы протесты нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советы карар итте:

1.Олы Мәңгәр авыл җирлеге Советының 2019 елның 11 ноябрендәге № 113 карары белән расланган ( № 127 10.02.2020 ел, № 131 28.05.2020 ел; № 7 30.10.2020 ел; № 35 06.12.2021 ел; № 48 16.05.2022 ел; № 52 17.08.2022 ел; № 82 27.10.2023 ел; № 96 05.06.2024 ел; № 116 21.04.2025 ел үзгәрешләре белән) " Олы Мәңгәр авыл җирлеге" муниципаль берәмлегендә бюджет процессы турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

**1.1** 21 статьяның 3 нче пунктының икенче, өченче һәм алтынчы абзацларында «муниципаль-шәхси партнерлык килешүләре ягыннан» дигән сүзләрдән соң «(гавами партнерның, капиталь грантнынт түләү күләмендә)» сүзләрен өстәргә;

**1.2.** 21 статьяның, 3 пунктының, дүртенче абзацында «Күрсәтелгән чикләүкагылмый» сүзләрен «Әлеге пунктның икенче һәм өченче абзацларындагы билгеләнгән чикләүләр кагылмый» сүзләренә алмаштырырга."

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Әтнә муниципаль районының рәсми сайтында http://atnya.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җавапчылыгымда калдырам.

Олы Мәңгәр авыл
җирлеге башлыгы — Филатова Ф.Ф.